ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10 август, 2018 ел № 26/8

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмалары һәм аерым муниципаль оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 412 санлы Карары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 41 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Расларга:

1) муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәне 1 нче кушымтада каралган тәртиптә;

2) муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәне 2 нче кушымтада каралган тәртиптә;

3) муниципаль өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәне 3 нче кушымтада каралган тәртиптә;

4) муниципаль белем бирү оешмаларында гомуми тармак эшче һөнәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификацион төркемнәре җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәне 4 нче кушымтада каралган тәртиптә.

2. Әлеге Карарның 1 пункты белән билгеләнгән муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренә билгеләнгән хезмәт хакы, җитәкчеләр һәм хезмәткәрләрнең хезмәт вазыйфалары күләме һәм квалификацияләре үзгәрешсез калган

очракта, Карар нигезендә хезмәт хакы түләүгә кадәр гамәлдә булган хезмәт хакына түләү системасындагы түләүдән ким булмаска тиешлеген билгеләргә.

3. Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/8 санлы Карары белән раслаган хезмәткә түләүнең яңа системасы кертелгән муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләү шартларын билгеләү турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2016 елның 08 июлендәге 9/8, 2016 елның 15 декабрендәге 13/9, 2017 елның 29 мартындагы 16/6, 2017 елның 10 августындагы 18/5, 2018 елның 21 февралендәге 23/8, 2018 елның 27 апрелендәге 24/7 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге эчтәлектәге 27.1 пунктын өстәргә:

«27.1. Башкарма комитет карары белән расланган аерым оешмаларның гомуми тармак эшче һөнәрләре квалификацион һөнәри төркеменә кергән «машина йөртүче» вазыйфасы хезмәткәрләренә эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр түбәндәгеләрне күздә тотып башкарыла:

1) катлаулылык һәм киеренкелек өчен түләү - окладның 75 проценты күләмендә

2) аеруча мөһим биремнәрне башкаручы машина йөртүчеләргә киеренкелек өчен түләү – вазыйфаи окладның 150 проценты күләмендә.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 35 нче пунктны өстәргә:

«35. Вазыйфаи оклад алучы аерым оешмаларның (Башкарма комитет карары белән раслана) гомуми тармак эшче һөнәрләрнең квалификацион һөнәри төркеменә кергән «машина йөртүче» вазыйфасы хезмәткәрләренә нормаль шартлардан аермалы (төрле квалификация эшләре башкару, һөнәрләрне (вазыйфаларны) бер үк вакытта башкару, эш сәгатеннән тыш эшләү, төнлә эшләү һ.б.) хезмәт өчен компенсацион түләүләр ял һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендәге эшкә түләү айлык эш вакыты нормасында башкарылган булса, окладка өстәмә рәвештә бермә-бер көндәлек яки сәгатьлек база ставкасы белән, эш айлык нормадан артып киткән очракта, база окладына өстәмә рәвештә ике көнлек яки сәгатьлек ставкадан ким булмаган күләмдә түләнелә.

4. Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге «Аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 24/7 санлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлектәге 4.1 пунктын өстәргә:

«4.1. Еллык хезмәт хакы күләме әлеге Карар гамәлгә кергәнче булган еллык хезмәт хакы күләменнән ким булмаска тиеш.»;

2) Аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәдә:

- 11 нче пунктка түбәндәге эчтәлектәге икенче һәм өченче абзацлар өстәргә:

«Башкарма комитет тарафыннан расланган муниципаль учреждение эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийларына туры килеп табыш китерүче эшчәнлекне оештыру өчен кергән керемнән түләү карала.

Учреждение хезмәткәрләренә табыш китерүче эшчәнлектән кергән керемнән түләү учреждениенең локаль актлары нигезендә башкарыла.»;

– 19 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 7 пунктча белән тулыландырырга:

«7) 2018 елның 31 мартында билгеләнгән аерым оешмаларның хезмәткәрләре вазыйфалары буенча еллык түләү күләме аермасын тигезләү максатында айлык түләү.»;

– 20 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«20. Аерым оешма җитәкчеләренә Башкарма комитет тарафыннан расланган муниципаль учреждение эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийларына туры килеп табыш китерүче эшчәнлекне оештыру өчен кергән керемнән түләү карала

Аерым оешма хезмәткәрләренә табыш китерүче эшчәнлектән кергән керемнән түләү учреждениенең локаль актлары нигезендә башкарыла.»;

– 22 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 6 пунктча белән тулыландырырга:

«6) 2018 елның 31 мартында билгеләнгән аерым оешмаларның хезмәткәрләре вазыйфалары буенча еллык түләү күләме аермасын тигезләү максатында айлык түләү, билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә (алга таба – аерманы тигезләү максатында айлык түләү).

Аерманы тигезләү максатында айлык түләүне хисаплаганда 2018 елның 31 мартына кадәр гамәлдә булган штат челтәрендәге вазыйфаи оклад һәм өстәмә түләүләр исәпкә алына.

Аерманы тигезләү максатында айлык түләү алынган матди яччрдәмне исәпкә алып башкарыла.»;

– 26 пункттагы өченче абзацны көчен югалткан дип танырга

5. Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/7 санлы Карары белән расланган «Янгыннан коткару отряды» муниципаль бюджет учреждениесенең аерым категория хезмәтәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәнең 11 пункты, 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) зыянлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен;».

6. Әлеге Карар, 2018 елның 01 сентябреннән гамәлгә керүче 1 нче пунктыннан һәм 2018 елның 01 апреленнән соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагылучы 4 нче пунтыннан тыш, рәсми бастырылган көннән гамәлгә керә.

Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге «Хезмәткә түләүнең яңа системасы кертелгән муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләү шартларын билгеләү турында» 39/8 санлы Карары (Шәһәр Советының 2016

елның 08 июлендәге 9/8, 2016 елның 15 декабрендәге 13/9, 2017 елның 29 мартындагы 16/6, 2017 елның 10 августындагы 18/5, 2018 елның 21 февралендәге 23/8, 2018 елның 27 апрелендәге 24/7 санлы Карарлары редакциясендә) 2018 елның 01 сентябреннән муниципаль белем бирү оешмалары, муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына һәм өстәмә белем бирү оешмаларына кагылмый.

7. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев